КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 октябрь г.Казань № 974

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә туклануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чаралары турында» 2020 ел, 21 май, 412 нче карары белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә туклануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын

йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланyны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чаралары турында» 2020 ел, 21 май, 412 нче карары белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланyны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибенә, 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан аерым хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен яңа коронавирус йогышы ачыкланган гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә һәм үз эшчәнлекләрен социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларга, шулай ук социаль хезмәт күрсәтү оешмасы хезмәткәрләренә, эш сменасының озынлыгы 14 календарь көннән дә ким булмаган очракта, вакытлыча изоляция (обсервация) 2020 елның 30 августына кадәр чикләү чараларын күздә тоткан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында аерым эш режимы турында" 2020 ел, 19 май, 406 нчы карары белән билгеләнгән аерым режимда башкара торган яңа коронавирус йогышы белән зарарлану куркынычы төркемендәге затларга социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирүгә тотыла.

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан аерым хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен яңа коронавирус йогышы ачыкланган гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә һәм үз эшчәнлекләрен социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларга, шулай ук социаль хезмәт күрсәтү оешмасы хезмәткәрләренә, эш сменасының озынлыгы 14 календарь көннән дә ким булмаган очракта, вакытлыча изоляция (обсервация) 2020 елның 15 ноябренә кадәр чикләү чараларын күздә тоткан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында аерым эш режимы турында" 2020 ел, 19 май, 406 нчы карары белән билгеләнгән аерым режимда башкара торган яңа коронавирус йогышы белән зарарлану куркынычы төркемендәге затларга социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирүгә тотыла.»

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин